ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

2024 елның «05» сентябре № 1200

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендалана торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен биш ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.

2. Сатып алына торган арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен (бер мәртәбә яисә өлешләп түләү), шулай ук арендалана

торган мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектының әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукына ия.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга. 4.Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә. 5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Хәйбрахманов И.Р.
5-44-72